# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлегенең Яңа Иркәнәш торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**28.11.2024ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Яңа Иркәнәш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Яңа Иркәнәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзсалым кертергә, 1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән, МХО зонасында хезмәт итүчеләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Иркәнәш торак пунктында хуҗасыз участокка койма кою, төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Иркәнәш торак пунтында сабантуй урынын җыештыру, скамейкалар, будка алу, урнаштыру, килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Иркәнәш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Минзәлә муниципаль районының сайтында бастырып чыгарырга (http://menzelinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы

Камалов И. З.